# Капитан булачакмын

Мәсгудә Шәмсетдинова көе
Роберт Миңнуллин сүзләре

♩ = 120




Ү - сеп җит - кәч мин ба - ры - бер
ка - пи - тан бу - ла - чак - мын,
Ко - ра - бым - ның ш - тур - ва - лын


туй - ган - чы бо - ра - чак - мын.
Я - ңа Грен-лан-ди-я-да,
па - пу - ас-лар и-лен-дә, юл-ба-рыс-лы Джун-гли -


да
йө - ри - сем бар ми - нем - дә,
йө - ри - сем бар ми - нем дә.
mf



Үсеп җиткәч мин барыбер,
Капитан булачакмын,
Корабымның штурвалын
Туйганчы борачакмын.
Кушымта:
Яңа Гренландиядә,
Папуаслар илендә,
Юлбарыслы джунглида,
Йөрисем бар минем дә,
Йөрисем бар минемдә.

Кораб белән мин иң ерак
Илләргә барачакмын,
Диңгезләрдә ачылмаган
Утраулар табачакмын.
Кушымта:
Яңа Гренландиядә,
Папуаслар илендә,
Юлбарыслы джунглида,
Йөрисем бар минем дә,
Йөрисем бар минемдә.

Диңгез давылына гына
Булыр иде түзәргә,
Ләкин башта ничек кенә
Өйрәнергә йөзәргә?
Кушымта:
Яңа Гренландиядә,
Папуаслар илендә,
Юлбарыслы джунглида,
Йөрисем бар минем дә,
Йөрисем бар минемдә.